**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫң ХАЙВАННАР ДӨНЬЯСЫ ОБЪЕКТЛАРЫН САКЛАУ һӘМ АЛАРДАН ФАЙДАЛАНУ ИДАРӘСЕ**

**БОЕРЫК**

13 февраль 2014 ел Казан шәһәре № 21-тэ

Татарстан республикасының
хайваннар дөньясы объектларын
саклау һәм файдалану Идарәсе
карамагында, балык тоту
урыннарының чикләрен билгеләү
һәм аның эш тәртибен раслау
буенча комиссия булдыру турында

Федераль канунның 18 маддәсенең 2 бүлеге 2004.20.12 № 166-ФЗ «Балыкчылык һәм су биологик байлыкларын саклау турында», Россия Федерациясенең Авыл хуҗалыгы министрлыгы боерыгы 2013.22.03. №143 6 пункты «Балык тоту урыннарының чиген билгеләү тәртибен раслау турында», Татарстан Республикасының Министрлар Кабинеты карары 2008.18.04. № 246 «Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе турында кагыйдәнамәне раслау» п.п. 2.1, 3.1, 4.1.11, 4.1.31 белән тәңгәл килеп, **б о е р а м:**

1. Расларга:

1.1. Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе карамагындагы, балык тоту урыннарының чикләрен билгеләү буенча Комиссиянең эшчәнлек тәртибе турында бирелгән кагыйдәнамәне;

1.2. Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе карамагындагы, балык тоту урыннарының чикләрен билгеләү Комиссиянең катнашмасын (1 кушымта);

2. Бу боерыкның үтәлү дәрәҗәсен тикшерүне үземдә калдырам.

Татарстан республикасының хайваннар
Дөньясы объектларын саклау һәм
файдалану Идарәсе башлыгы Д.А. Иванов

Татарстан республикасының
хайваннар дөньясы объектларын
саклау һәм файдалану
Идарәсе белән
РАСЛАНГАН
№ 21-тэ 13.02.2014 елдан

**Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе карамагындагы, балык тоту урыннарының чикләрен билгеләү буенча Комиссиянең эшчәнлек тәртибе турында кагыйдәнамә.**

## 1. Гомуми кагыйдәнамәләр

1.1 Гамәлдәге кагыйдәнамә Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе карамагындагы, балык тоту участокларының чикләрен билгеләү буенча Комиссиянең максатларын, бурычларын һәм эшчәнлек оештырылуы нигезләрен билгели (аннары – Комиссия). Кагыйдәнамә Федераль канунның 18 маддәсенең 2 бүлеге 2004.20.12 № 166-ФЗ «Балыкчылык һәм су биологик байлыкларын саклау турында» , Россия Федерациясенең Авыл хуҗалыгы министрлыгы боерыгы 2013.22.03. №143 6 пункты «Балык тоту урыннарының чиген билгеләү тәртибен раслау турында», Татарстан республикасының Министрлар Кабинеты карары 2008.18.04. № 246 «Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе турында кагыйдәнамәне раслау» п.п. 2.1, 3.1, 4.1.11, 4.1.31 белән тәңгәл килеп эшләнде.

1.2. Гамәлдәге кагыйдәнамә текстында түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланылды:

балык тоту участогы – хокукый затларга һәи шәхси эшмәкәрләргә сәнәгый балык тоту өчен бүленеп бирелгән, сулык мәйданы участогы.

комиссия – балык тоту участокларының исемлеге проектларының чикләрен раслау өлешен карап тикшерү өчен оештырылган комиссия.

1.3. Балык тоту участокларын сайлап алу проекты, Татарстан республикасының эчке суларында экономик һәм экологик яклардан биологик су ресурсларын балансланган файдалану максаты белән булдырыла.

1.4. Комиссия Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе карамагында булдырыла һәм гел эшләп торучан була.

1.5. Комиссия Россия Федерациясе Конституциясен, Татарстан республикасы Конституциясен, федераль конституцион кануннарны, федераль кануннарны, Россия Федерациясе Президенты һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте гамәлләрен, Татарстан республикасы Президенты һәм

Татарстан республикасы Хөкүмәте гамәлләрен, башка норматив хокукый гамәлләрне, ә шулай ук гамәлдәге кагыйдәнамәне кулланып эш итә.

1.6. Комиссия әгъзалары үзләренең вазыйфаларын иҗтимагый рәвештә үтиләр.

1.7.Комиссия эшчәнлеге бөтен сорауларны фикер алышу һәм коллектив чишелеш чыгару нигезендә тормышка ашырыла.

## 2. Комиссиянең бурычлары һәм максатлары

2.1. Комиссия алдында Татарстан республикасының балык тоту участокларының проект чиге буенча тәкъдимнәр кертү һәм аларны карау бурычы тора.

2.2. Комиссия Татарстан республикасының эчке сулыкларында булган биологик су ресурсларын, икътисади һәм экологик күзлектән чыгып, балансланган кәсепне тәэмин итүгә булышлык максаты белән оештырыла.

## 3. Комиссиянең оештырылу тәртибе

3.1. Комиссия әгъзалары булып, 18 яшькә җиткән, Россия Федерациясе гражданнары килә алалар.

3.2. Комиссия катнашмасына башкарма хакимиятнең территориаль әгъза вәкилләре, Татарстан республикасының башкарма хакимият әгъза вәкилләре, җирле үзидәрә әгъза вәкилләре, иҗтимагый оешма вәкилләре, хокукый затлар берләшмәсе һәм гыйльми оешмалар вәкилләре кертеләләр.

3.3. Комиссия 32 кеше катнашмасында төзелә.

3.4. Комиссия катнашмасы Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе башлыгы боерыгы белән раслана.

3.5. Комиссия рәистән, аның урынбасарыннан, комиссия әгъзаларыннан тора.

3.6. Рәис, рәиснең урынбасары һәм комиссия сәркатибе Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе башлыгы боерыгы белән раслана.

3.7. Комиссия әгъзасы булудан туктау, Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе башлыгы, Комиссия әгъзасыннан яки аның вәкиленнән, язмача гариза алу нәтиҗәсендә кабул ителгән чишелеше белән тәңгәл килеп, тормышка ашырыла.

## 4. Комиссиянең эш тәртибе

4.1. Комиссиянең тикшерү предметы булып, Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе белән бирелгән Проект тора.

4.2. Комиссия Проектны, бирелү көненнән алып, 3 көн эчендә тикшерә.

4.3. Комиссиянең Проект буенча чишелеше һәм тәкъдимнәре Комиссия утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә. Беркетмәгә Комиссия рәисе (ул булмаган очракта – утырышны алып баручы Комиссия Рәисе урынбасары),

Комиссия Рәисе урынбасары, Комиссия сәркатибе, ә шулай ук утырышта булган барлык Комиссия әгъзалары кул куялар.

4.4. Комиссия әгъзасы кабул ителгән чишелеш белән килешмәсә, ул үз фикерен язмача рәвештә аңлатып бирә ала. Аның фикерен, шулай ук, Комиссия утырышы беркетмәсенә теркәп куялар.

4.5. Комиссия утырышы беркетмәсе, имзалар куйганнан соң, Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсенә 1 эш көне эчендә җибәрелә.

4.6. Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе, Татарстан Республикасының рәсмиләштерелгән балык тоту участокларына үзгәртүләр кертү турында проект бирү очрагында, гамәлдәге кагыйдәнамәдә каралган Комиссиянең эш тәртибе эшли башлый.

## 5. Комиссия эшчәнлегенең оештырылуы

5.1. Комиссиянең төп эшчәнлек төре – утырышлар. Алар Татарстан Республикасында балык тоту участокларының исемлеген төзү вакытында үткәреләләр.

5.2. Комиссия рәисе:

Комиссия белән җитәкчелек итә, аның утырышларында рәислек итә;

Комиссия эшчәнлеген оештыра һәм алып бара;

Комиссия утырышларын уздыру турында карар кабул итә;

Комиссия утырышының көн тәртибен билгели;

Комиссия утырышларының беркетмәләрен раслый;

Комиссия өстенә салынган вазыйфаларның тулы һәм үз вакытында үтәлүе өчен шәхси җаваплылык тота.

5.3.Комиссиянең Рәисе урынбасары, рәис булмаган чакларда, аның вазыйфаларын үти.

5.4.Комиссия сәркатибе:

Комиссия әгъзаларына һәм бүтән кызыксынган затларга Комиссия утырышы булуы турында хәбәр итә;

Бирелгән гаризаларны кабул итә һәм теркәп куя;

Комиссия утырышына әсбаплар әзерли;

Комиссия утырышының беркетмәләрен һәм алардан өземтәләрне рәсмиләштерә;

5.5. Утырышта 50% артык Комиссия әгъзалары катнашса, Комиссия утырышы хокуклы булып санала.

5.6. Хокуклы Комиссия утырышы чикләрендә, Комиссиянең чишелешләре күпчелек ачык тавыш белән билгеләнә.

Тавышлар тигез булган очракта,рәиснең тавышы, ул булмаган очракта, аның урынбасары тавышы, хәлиткеч булып санала.

5.7. Оештырма–техник яктан Комиссия эшчәнлеген Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе тәэмин итә.

Татарстан республикасының
хайваннар дөньясы объектларын
саклау һәм файдалану
Идарәсе боерыгына
1 нче кушымта
№ 21-тэ 13.02.2014 елдан

**Балык тоту участокларының чикләрен билгеләү буенча Комиссия катнашмасы**

| № | Оешма | Хезмәт | Ф.И.О. |
|---|---|---|---|
| 1 | Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе | башлык | Иванов Дмитрий Алексеевич – Комиссия рәисе |
| 2 | Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе | Башлыкның урынбасары | Батков Фёдор Сергеевич – Комиссия рәисе урынбасары |
| 3 | Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе | Хайваннар дөньясы объектларын файдала-нуны лицензияләү, исәпкә алу, тәртипкә, рәткә салу, кадастр бүлеге башлыгы | Чиспияков Ринат Электронович – Комиссия сәркатибе |
| 4 | Татарстан республика-сының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе | Алдагы киңәшче | Павлов Юрий Ирекович |
| 5 | Татарстан республикасының ветеринар һәм фитосанитар тикшерү буенча федераль хезмәт Идарәсе | Дәүләт ветеринар тикшерү бүлеге башлыгының урынбасары | Ефимов Руслан Владимирович (килешү буенча) |
| 6 | Татарстан республикасында табигать куллану өлкәсен тикшерү буенча федераль хезмәт Идарәсе | Идарәнең башлыгы урынбасары | Гайнутдинова Лилия Әхәт кызы (килешү буенча) |
| 7 | Татарстан республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы | Аерым саклана торган территорияләрдә биологик төрлелекнең торы-шын тикшерү буенча махсус инспек-ция башлыгы. | Гуляев Александр Мартикович (килешү буенча) |
| 8 | ФГБУ «Средневолжрыбвод» Балык тоту һәм Татарстан респуб-ликасының биологик су ресурс-ларын саклау буенча филиалы. | Алдагы ихтиолог | Богатырев Илья Александрович (килешү буенча) |
| 9 | Татарстан республикасының | Рәис | Нәбиев Флюр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Әгерҗе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәте палатасы | | Фәйзиевич (килешү буенча) |
| 10 | Татарстан Республикасының Алексеевск муниципаль районының Киңәше | Аппарат җитәкчесе | Белкин Александр Леонидович (килешү буенча) |
| 11 | Татарстан республикасының Актаныш муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәте палатасы | Рәис урынбасары | Нәзмиев Ленар Марсель улы (килешү буенча) |
| 12 | Татарстан Республикасының Алабуга муниципаль районының МКУ Җир-мөлкәт палатасы | Рәис | Петров Евгений Юрьевич (килешү буенча) |
| 13 | “ Яшел Үзән муниципаль районының төзлеш һәм аскорма үсеше буенча Департамент» | Башлык | Багаутдинов Ильсур Хәмит улы (килешү буенча) |
| 14 | Татарстан республикасының Кама Тамагы муниципаль районының башкарма комитеты | Экономика буенча җитәкче урынбасары | Юманов Дмитрий Витальевич (килешү буенча) |
| 15 | Татарстан республикасының Мамадыш муниципаль районының башкарма комитеты | Җитәкче урынбасары | Дәрҗеманов Ильшат Миннәсхәт улы (килешү буенча) |
| 16 | Татарстан республикасының Минзәлә муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәте палатасы | Рәис | Садыкова Фәрида Мәсгут кызы (килешү буенча) |
| 17 | Татарстан республикасының Минзәлә муниципаль районының Мал эшләре – мизания һәм Җир - мөлкәт палатасы | Мөлкәт мөнәсәбәте бүлеге башлыгы, рәис урынбасары | Якупова Ләйсән Нәзиф кызы (килешү буенча) |
| 18 | Татарстан республикасының Түбән Кама муниципаль районының башкарма комитеты | Башлыкның киңәшчесе | Федотов Владимир Васильевич (килешү буенча) |
| 19 | Татарстан республикасының Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәте палатасы | Рәис | Рәшитов Роберт Рафыйк улы (килешү буенча) |
| 20 | Татарстан республикасының Спас муниципаль районының башкарма комитеты | Экономика буенча җитәкче урынбасары | Закирова Рушания Ризван кызы (килешү буенча) |
| 21 | Тәтеш муниципаль районының Киңәшмә аппараты | Тәтеш муниципаль районының Киңәшмә аппараты башлыгының бурычларын үтәүче | Салихов Ильшат Вәсил улы (килешү буенча) |
| 22 | Татарстан республикасының Тукай муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәте | Рәис урынбасары | Русский Сергей Валентинович (килешү буенча) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | палатасы | | |
| 23 | “ Чистай муниципаль районы” оешмасының башкарма комитеты | Чистай муниципаль районының тирә-як буенча белгече | Тесаков Олег Анатольевич (килешү буенча) |
| 24 | Казан (Идел буе) Федераль Университеты | Фундаменталь медицина һәм биология институтының биоэкология кафедрасы мөдире | Рәхимов Ильгизәр Ильяс улы (килешү буенча) |
| 25 | Казан (Идел буе) Федераль Университеты | Фундаменталь медицина һәм биология институты биоэкология кафедрасының өлкән мөгаллиме | Сәйфуллин Рөстәм Рашит улы (килешү буенча) |
| 26 | Ижтимагый оешма «Татарстан балыкчылары» | Рәис | Степанцов Виктор Алексеевич (килешү буенча) |
| 27 | Ижтимагый оешма «Татарстан балыкчылары» | Ижтимагый оешманың вәкиле | Мазанов Олег Валерьевич (килешү буенча) |
| 28 | Дәүләт бюджет оешмасы «Татарстан республика-сының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану өлкәсендә яңа технологияләр кертү үзәге» | Директор | Шарафутдинов Рамиль Гомәр улы (килешү буенча) |
| 29 | Региональ ижтимагый оешма “ Татарстан республикасының аучылар һәм балыкчылар оешмасы” | Вәкил | Гарипов Олег Наилевич (килешү буенча) |
| 30 | Ижтимагый-дәүләт оешмасы “Татарстан республикасының “Динамо” спорт оешмасы” | Вәкил | Газизов Нурмөхәммәт Габделкәбир улы (килешү буенча) |
| 31 | Казан горнизонының Хәрби - аучылык җәмгыяте – Идел буе хәрби округының регионара спорт ижтимагый оешмасының хәрби-аучылык җәмгыяте оешмасы | Киңәшмә рәисе | Трифонов Олег Михайлович (килешү буенча) |
| 32 | Актаныш районының аучылар һәм балыкчылар жирле ижтимагый оешмасы | Вәкил | Ахметов Фирдәвес Гаяз улы (килешү буенча) |